МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.01.2023 Казан ш. № п/11

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүгә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

Министр А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы
Дәүләт идарәсен цифрлы
нигездә үстерү, мәгълүмат
технологияләре һәм элемтә
министрлыгының 2023 елның
16 гыйнварындагы п/11
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – Учреждение) дәүләт хезмәтләрен күрсәтү (эшләр башкару) өчен дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү механизмын билгели.

2. Субсидияләр Учреждениегә түбәндәге максатларда бирелә:

«2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү;

Учреждение эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә;

Учреждениедә укучыларны туклану белән тәэмин итүгә;

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы указын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга;

яңа хезмәт хакы системасын кертүгә;

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга;

мөлкәт сатып алуга;

чыгымнар дәүләт хезмәте күрсәтүгә (эш башкаруга) норматив чыгымнар исәбенә кертелмәгән очракта, Учреждениенең төп эшчәнлеген алып баруга бәйле башка чараларны гамәлгә ашыруга.

3. Учреждениегә субсидияләр, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия алу өчен Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

аңлатма язуын, анда бюджет акчаларын бирү зарурлыгын нигезләү, шул исәптән субсидия суммасын исәпләү-нигезләү, шулай ук тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә), чаралар уздыруга, мөлкәт сатып алуга (күчемсез мөлкәттән тыш) башлангыч смета, шулай ук тәэминатчыларның (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәре, статистика белешмәләре һәм (яки) башка мәгълүмат була;

субсидия бирүнең максаты әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче, тугызынчы абзацлары нигезендә чаралар үткәрү булса, чаралар программасы;

субсидия бирү максаты мөлкәтне сатып алу булса, сатып алуга планлаштырылган мөлкәт турында мәгълүмат;

түләүләрне алучылар булып торган физик затларның саны (уртача еллык саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат, әгәр субсидия бирү максаты булып Учреждение хезмәткәрләренә түләүләр башкару торса;

субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның 1 нче көненә булган торышында Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләренең булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

килешү төзү планлаштырыла торган айдан алда килгән айның 1 нче көненә Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычларының булмавы турында җитәкче һәм баш бухгалтер, вәкаләтле башка зат тарафыннан имзаланган белешмә.

Тапшырылган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Документларның күчермәләре Учреждениенең мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән таныкланган булырга тиеш.

Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән расланган булырга тиеш.

Учреждение тарафыннан документлар, электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып, электрон рәвештә җибәрелгән очракта, алар Учреждение җитәкчесенең яисә Учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

5. Субсидия алу өчен документлар Гамәлгә куючы тарафыннан алынган көнне журналда теркәлә, ул номерланырга, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Министрлык әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң биш эш көне эчендә андагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

6. Учреждение килешү төзү планлаштырыла торган айдан алда килгән айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычлары юк.

7. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 4 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет законнары нигезендә Министрлыкка җиткерелгән, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларының тиешле күләмдә булмавы.

8. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган документларны Министрлыкка кабат тапшырырга хокуклы.

9. Субсидиянең күләме Учреждение тапшырган документлар нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында тиешле финанс елына һәм план чорына каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, субсидия бирү максатына бәйле рәвештә хокукый актларда һәм башка документларда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып билгеләнә, субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклардан тыш.

10. Субсидия бирү максатларына карап, аны бирү нәтиҗәләре:

субсидия чараларны үткәрүгә бирелгән очракта, үткәрелгән чаралар саны;

Учреждениенең Укыту үзәге эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә бирелгән субсидия хисабына кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә);

Учреждениенең «ИТ-cube» Балалар ИТ-иҗат үзәгендә түләүсез нигездә белем алган балалар саны, субсидия югарыда күрсәтелгән балалар үзәге эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә бирелгән очракта;

субсидия һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыру өчен бирелгән очракта, Учреждениедә укучыларга туклану өчен тулы күләмендә акча чаралары бирү (100 процент күләмендә);

хезмәт хакының яңа системасын кертүгә һәм Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы указын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә субсидияләр исәбеннән түләүләр алган хезмәткәрләр саны;

субсидия мөлкәт сатып алуга бирелгән очракта, сатып алынган мөлкәт объектлары саны.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү вакыты – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

11. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә Министрлык һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма буенча килешү (алга таба – килешү) төзиләр, анда, шул исәптән, түбәндәгеләр була:

субсидия бирү максатлары;

субсидияне бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

субсидиянең күләме;

субсидияне күчерү вакыты (графигы);

хисаплылык тапшыру чорлары һәм тәртибе;

Учреждение килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;

Министрлык карары буенча берьяклы тәртиптә килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерүгә (кушылдыру формасында үзгәртеп корудан тыш) һәм Учреждение тарафыннан әлеге Тәртип һәм (яки) килешү нигезендә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуга бәйле рәвештә дә;

Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә.

Кирәк булуга карап, Министрлык һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәкләр нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Министрлык килешүдә каралган чорда субсидияне Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерә.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

13. Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

хисап аеннан соңгы айның 10нчы көненнән соңга калмыйча, ай саен, финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисаплылык;

ел саен, агымдагы финанс елының 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм финанс хисап елы өчен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында хисап.

Хисапларның формалары килешүдә билгеләнә.

14. Министрлык килешүдә өстәмә хисаплылык бирү формаларын һәм чорларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидияне бирү максатлары, шартлары үтәлешенә контрольлекне һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

15. Хисап финанс елында кулланылмаган субсидия акчаларының калган өлеше (алга таба – субсидиянең калган өлеше) хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш, Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул ителгән очрактан тыш.

Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булган очракта, Учреждение хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан соңга калмыйча Министрлыкка финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган субсидиянең калдык өлеше торган, Учреждениенең үтәлмәгән йөкләмәләре турындагы мәгълүматны, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләренең булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен) җибәрә (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш).

Министрлык Учреждениедән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән соң өч эш көне узганчы агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калдык өлешен әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калдык өлешен әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул иткән очракта, Министрлык белән Учреждение арасында мондый карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек чорда килешүгә өстәмә килешү төзелә.

16. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр (алга таба – дебиторлык бурычын кире кайтарудан алынган акчалар) торган, Учреждение тарафыннан элегрәк кайтарылган түләүләрдән килгән акчалар булган очракта, Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып дебиторлык бурычын кире кайтарудан алынган акчалар торган, үтәлмәгән

йөкләмәләре булуы турындагы мөрәҗәгате, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләренең булуы һәм күләме турындараслый торган документлар (документларның күчермәләре) (физик затларга булган түләүләр буенча йөкләмәләрдән кала) нигезендә Министрлык аларны Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен файдалану турында карар кабул итә.

Министрлык Учреждениедән әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән соң өч эш көне узганчы агымдагы финанс елында дебиторлык бурычларын кире кайтарудан алынган кулланылмаган акчаларны әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы Учреждениегә субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлүгә карата мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Акчаларны максатчан тотму Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылык китереп чыгара.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланып, Учреждение субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәгән, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракларда, субсидия тиешле таләп Учреждение тарафыннан алынган көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда Учреждение тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирелергә тиеш.

Субсидия акчаларын Учреждение тарафыннан кире кайтару чорлары бозылган очракта, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чор беткән көннән соң 30 көнлек чорда законнарда билгеләнгән тәртиптә субсидия акчаларын Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.